СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**от « 16 » июль 2021 г.** **№ 25**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы КАРАРЫ авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы КАРАРЫ авыл җирлеге Советының 22.10.2018ел, № 60 карарына үзгәрешләр кертү турында (20.12.2018ел № 71, 18.12.2020 №13 үзгәрешләр белән)**

«Территорияләрне комплексլы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 22.10.2018 ел, №60 карарына (20.12.2018ел №71, 18.12.2020 №13 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар (алга таба - җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3_1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка

җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин.